**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КРАСНОСЕЛЬСКИЙ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет ур., 13

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**КРАСНОСЕЛЬСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru


**КАРАР**
**30 сентябрь 2020 ел**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 18**

## Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерының һәм бухгалтерларының хезмәтенә (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан кала) түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 05 августындагы 655 нче номерлы «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» карары нигезендә Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты, **КАРАР БИРӘ**:

1. 2020 елның 1 октябреннән бухгалтерларның айлык вазыйфаи окладлары күләмен (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) 1,03 тапкырга арттырырга.
2. Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 21 октябрендәге 29 нче номерлы «Бердәм тариф челтәре кагылмый торган Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтер һәм бухгалтерлар, бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында» карары белән расланган «Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты баш бухгалтерының һәм бухгалтерларының хезмәтенә (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан кала) түләү шартлары турында» Нигезләмәнең 3 пунктына «Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең бухгалтерларның вазыйфаи окладлары» таблицасына (2019 елның 26 декабрендәге 35 нче номерлы Карары редакциясендә) түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

| Вазыйфа | Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары халык саны белән | |
|---|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр | 3,5 мең кешедән артыграк |
| Баш бухгалтер | 16171 | 17510 |
| Бухгалтер | | 14935 |

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам

Красносельский авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе И.З.Газизов